ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан ш.

14.06.2019 № 70

2019 елда «Туристлык лидеры» республикакүләм бәйгесен үткәрү турында

21.07.2014 дан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 522-нче номерлы ««Татарстан Республикасында 2014-2022 елларга туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карар нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасындагы туристлык базарының ин яхшы катнашучылары һәм юнәлешләрен ачыклау максатыннан боерык бирәм:

1. 2019 елда «Туристлык лидеры» республикакүләм бәйгесен үткәрү турындагы Нигезләмәне расларга (алга таба – Бәйге).
2. Татарстан Республикасы туристлык буенча Дәүләт комитетының 16.04.2018 нән 33-нче номерлы «2018 елда «Туристлык лидеры» республика бәйгесен үткәрү турында» карары көчен югалткан дип танырга.
3. Туристлык тармагын үстерү бүлегенә (А.В.Софьина) Бәйгене әзерләү һәм үткәрү буенча эшне оештырырга.
4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны рәис урынбасары Е.А.Барабановага йөкләргә.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан Республикасының
туристлык буенча
Дәүләт комитетының
14.06.2019 дан 70 номерлы
боерык буенча расланган

2019 елда «Туристлык лидеры» республикакүләм бәйгесен үткәрү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2019 елда «Туристлык лидеры» (алга таба – Бәйге) республикакүләм бәйгесе тәртибен, үткәрү һәм оештыру шартларын, шулай ук Бәйгедә катнашучылар, бәйге документлары һәм аларның Бәйгегә тапшырылу тәртибе өчен таләпләр, Бәйгенең үткәрү вакытларын билгели.

1.2. Бәйгенең максатлары туристлык базарында ин яхшы катнашучыларны һәм юнәлешләрне ачыклау, Татарстан Республикасы икътисадының үсешенә шактый зур өлеш кертә торган Татарстан Республикасында хәзерге заман югары эффектлы һәм көндәшлеккә сәләтле туристлык комплексын булдыру мәсьәләләрен чишү өчен туристлык эшмәкәрлегенең тырышлыгын берләштерү һәм юнәлтү.

1.3. Бәйгенең оештыручысы Татарстан Республикасының туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) булып тора. Бәйге аны оештыручларның берсе буларак катнашучы туристлык өлкәсендә эшчәнлек алып баручы кызыксынган оешмалар белән берлектә үткәрелә.

1.4. Бәйгене финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.07.2014 нән 522-нче номерлы карары белән расланган «2014-2022 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәләрен үстерү» дәүләт программасы белән каралган акчалар хисабына башкарыла.

2. Бәйгедә катнашу шартлары

2.1. Бәйгедә катнашу түләүсез, ирекле нигездә башкарыла.

2.2. Бәйгедә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән туристлык индустриясе субъектлары (шул исәптән урнаштыру оешмалары һәм күмәк чаралары, шул исәптән шифаханә һәм курортларда дәвалау һәм ял итү, белемне киңәйтү, эшлеклелек, дәвалау һәм сәламәтләндерү һәм башка максатлы оешмалар, шулай ук туроператорлык һәм турагентлык эшчәнлеген башкаручы оешмалар һ.б.), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары, Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмалар, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары (гәзитләр, журналлар, радио, телевидение), шулай ук 22 яшьтән 60 яшькә кадәр булган физик затлар катнаша.

2.3. Бәйгедә катнашу өчен номинантларны күрсәтү ничек юрик һәм шулай ук физик затлар тарафыннан башкарыла. Бәйгедә катнашу бер яки берничә номинациядә (теләк буенча) башкарыла.

## 3. Бәйгене оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Бәйге бер этапта 2019 елның 1-нче августыннан 25 декабренә кадәр үткәрелә.

Бәйгене үткәрү турында мәгълүмат мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) (алга таба – Дәүләт комитетының сайты) бәйге документларын кабул итү башланганырга 15 көннән дә соңрак түгел кала урнаштырыла.

3.2. Бәйге документларын Дәүләт комитетына тапшыру вакыты 2019 елның 1-нче августыннан 1 декабренә кадәр (1 декабрьне исәпкә алып).

Бәйге документлары 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., М.Горький ур., 19 йорт (1-нче кабинет) адресы буенча кулга тапшырыла яки почта аша җибәрелә.

Бәйге документларының электрон версиясе шулай ук Бәйгене оештыручының электрон адресына - Olga.Neumoina@tatar.ru га юнәлтелә.

3.3. Бәйгедә катнашуга эчтәлеге һәм төзелеше әлеге Нигезләмәнең таләпләренә җавап бирүче әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән вакыт аралыгында тапшырылган бәйге документлары кабул ителә.

3.4. Бәйгедә катнашу өчен Дәүләт комитетына тутырылган сораунамә-гариза (формалары теркәлгән) һәм әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында күрсәтелгән номинациягә карата документлар тапшырыла.

3.5. Бәйге киләсе номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Ел ачышы – 2019».

2) «Татарстан Республикасы туристлык базарын үстерүгә булышлык» – киләсе бүлекләр буенча:

«Муниципаль туристлык сәясете өлкәсендә – 2019»;

«Туристлык белеме өлкәсендә – 2019»;

«Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә – 2019» – «Татарстан Республикасының керү туристлыгын һәм эчке туристлыкны поплярлаштыруга багышланган иң яхшы материал».

3) «2019 ел шәхесе – туристлыкны үстерүгә шәхси өлеш керткән өчен».

4) «Татарстан Республикасы буенча 2019 елның иң яхшы маршруты».

5) «2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы балалар туристлыгы туроператоры».

6) «Татарстан Республикасының 2019 елның иң яхшы туроператоры».

7) «2019 елның иң яхшы туристлык волонтеры».

8) «2019 елның иң яхшы экскурсия җитәкчесе».

9) «2019 ел туристлык истәлекле бүләге».

10) «Татарстан Республикасының урнаштыру оешмасы - 2019» – бүлекләр буенча:

«2019 елның иң яхшы 5 йолдызлы кунакханәсе»;

«2019 елның иң яхшы 4 йолдызлы кунакханәсе»;

«2019 елның иң яхшы 3 йолдызлы кунакханәсе»;

«2019 елның иң яхшы 2 йолдызлы кунакханәсе»;

«2019 елның иң яхшы йолдызсыз кунакханәсе»;

«2019 елның иң яхшы хостелы»;

«2019 елның иң яхшы шифаханәсе»;

«2019 елның иң яхшы мотеле».

11) «2019 ел рестораны».

12) «2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы шифаханәсе».

3.6. «Ел ачышы – 2019» номинациясендә катнашу өчен Бәйгегә 2019 елда тормышка ашырылган туристлык өлкәсендә булган проект теркәлгән сораунамә-гариза (1-нче номерлы Кушымта) тапшырыла.

«Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының туристлык базарын үстерүгә булышлык - 2019» номинациясендә сораунамә-гаризада (2-нче номерлы Кушымта) китерелгән махсус күрсәткечләр буенча Татарстан Республикасының туристлыгын үстерүгә өлеш керткән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары бәяләнә.

«Туристлык белеме өлкәсендә Татарстан Республикасының туристлык базарын үстерүгә булышлык - 2019» номинациясендә сораунамә-гаризада (3-нче номерлы Кушымта) китерелгән махсус күрсәткечләр буенча Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмалар бәяләнә.

«Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә Татарстан Республикасының туристлык базарын үстерүгә булышлык - 2019» номинациясендә Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары (газитләр, журналлар, радио, телевидение) бәяләнә. Бәйгегә 2019 елда бастырылган материаллар теркәлгән сораунамә-гариза (4-нче номерлы Кушымта) тапшырыла.

«2019 ел шәхесе – туристлыкны үстерүгә шәхси өлеш керткән өчен» номинациясендә катнашу өчен Бәйгегә физик зат тарафыннан яки оешма исеменнән тутырылган сораунамә-гариза (5-нче номерлы Кушымта) тапшырыла.

Бәйгедә катнашу өчен мәҗбүри шарт булып 2019 елда Татарстан Республикасы тикшерү әгъзалары: Кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтү буенча Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы

буенча Идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе, Федераль монополиягә каршы көрәш хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе - тарафыннан Бәйгедә катнашучыларга карата дәгъваларның юклыгы тора.

«Татарстан Республикасы буенча 2019 елның иң яхшы маршруты», «2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы балалар туристлыгы туроператоры», «Татарстан Республикасының 2019 елның иң яхшы туроператоры», «2019 елның иң яхшы туристлык волонтеры», «2019 елның иң яхшы экскурсия җитәкчесе», «2019 ел туристлык истәлекле бүләге», «Татарстан Республикасының урнаштыру оешмасы - 2019», «2019 ел ресторанЫ», «2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы шифаханәсе» номинацияләре буенча бәйге аны оештыручылар тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктына муафыйк үткәрелә.

Бәйгене оештыручалар Бәйге турындагы нигезләмәне раслый, Бәйген үткәрү тәртибен, шартларын һәм аны оештыруны, шулай ук Бәйгедә катнашучыларга, бәйге документларына һәм аларны Бәйгегә тапшыру тәртибенә кагылган таләпләрне, Бәйгене үткәрү вакытын билгели.

«Татарстан Республикасы буенча 2019 елның иң яхшы маршруты», «2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы балалар туристлыгы туроператоры» һәм «Татарстан Республикасының 2019 елның иң яхшы туроператоры» номинацияләре буенча Бәйге үткәрүне оештыручылары арасында Татарстан Республикасы туристлык агентлыклары берләшмәсе катнаша.

«Татарстан Республикасы буенча 2019 елның иң яхшы маршруты», «2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы балалар туристлыгы туроператоры» һәм «Татарстан Республикасының 2019 елның иң яхшы туроператоры» номинацияләре буенча Бәйгене үткәрү турындагы мәгълүмат мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә Татарстан Республикасы туристлык агентлыклары берләшмәсенең рәсми сайтында (http://atart.ru) урнаштырыла.

«2019 елның иң яхшы туристлык волонтеры» номинациясе буенча Бәйге үткәрүне оештыручыларның берсе булып «Татарстан Республикасының туристлык волонтерлары берләшмәсе» үзидарәле коммерцияле булмаган оешма катнаша.

«2019 елның иң яхшы туристлык волонтеры» номинациясе буенча Бәйге үткәрү турындагы мәгълүмат мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә «Татарстан Республикасының туристлык волоннтерлары берләшмәсе» үзидарәле коммерцияле булмаган оешманың «ВКонтакте» һәм «Инстаграм» дагы рәсми битләрендә (https://vk.com/atv2009, @atv_volunteers) урнаштырыла.

«2019 елның иң яхшы экскурсия җитәкчесе» номинациясе буенча Бәйге үткәрүне оештыручыларның берсе булып «Татарстан экскурсия җитәкчеләре» берләшмәсе тора.

«2019 елның иң яхшы экскурсия җитәкчесе» номинациясе буенча Бәйге үткәрү турындагы мәгълүмат мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет”

челтәрендә «Татарстан экскурсия җитәкчеләре» берләшмәсенең рәсми сайтында (http://kazantravel.ru) урнаштырыла.

«2019 ел туристлык истәлекле бүләге» номинациясе буенча Бәйге үткәрүне оештыручылары арасында булып «Татарстан Республикасы халык сәнгате һөнәрләрен һәм кәсепләрен үстерү Үзәге» дәүләт бюджет оешмасы, «Татарстан Республикасы халык сәнгате һөнәрләре һәм кәсепләре Палатасы» коммерцияле булмаган партнерлык катнаша.

«2019 ел туристлык истәлекле бүләге» номинациясе буенча Бәйге үткәрү турындагы мәгълүмат мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә Татарстан Республикасы халык сәнгате һөнәрләрен һәм кәсепләрен үстерү Үзәге» дәүләт бюджет оешмасының рәсми сайтында (http://remeslo.tatarstan.ru) урнаштырыла.

«2019 ел рестораны» номинациясе буенча Бәйге оештыручыларның берсе булып «Ресто-бюро» җаваплыгы чикләнгән оешма катнаша.

«2019 ел рестораны» номинациясе буенча Бәйге үткәрелү турында мәгълүмат Интернет челтәрендә WHERETOEAT Милли ресторан премиясенең рәсми сайтында урнаштырыла (http://tatarstan.wheretoeat.ru/).

«Татарстан Республикасы урнаштыру оешмасы - 2019» номинациясе буенча Бәйге оештыручыларның берсе булып Казан ш. һәм Татарстан Республикасы кунакханәләр Ассоциациясе катнаша.

«Татарстан Республикасы урнаштыру оешмасы - 2019» номинациясе буенча Бәйге үткәрелү турында мәгълүмат Интернет челтәрендә Казан ш. һәм Татарстан Республикасы кунакханәләр Ассоциациясенең рәсми сайтында урнаштырыла (https://aokrt.ru).

«2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы шифаханәсе» номинациясе буенча Бәйге оештыручыларның берсе булып «Татарстан шифаханәләре» шифаханә-курортлар Ассоциациясе катнаша.

«2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы шифаханәсе» номинациясе буенча Бәйге үткәрелү турында мәгълүмат Интернет челтәрендә Татарстан шифаханәләре» шифаханә-курортлар Ассоциациясе Ассоциациясенең рәсми сайтында урнаштырыла (http://san.tatar/).

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән вакыттан соңрак тапшырылган Бәйге документлары каралмый һәм Бәйгедә катнашуга үткәрелми.

3.8. Бәйгегә җибәрелгән барлык материаллар да кире кайтарылмый һәм рецензияләнми.

## 4. Сайлап алу тәртибе

4.1. Кабул ителгән бәйге проектларын бәяләү максаты белән Дәүләт комитеты тарафыннан Бәйге комиссиясе барлыкка китерелә (алга таба - Комиссия).

4.2. Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм җаваплы сәркатибе җитәкчелегендәге республика башкарма хакимияте әгъзалары һәм Татарстан

Республикасы иҗтимагый оешмалары вәкилләре, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында күрсәтелгән номинацияләр буенча Бәйге үткәрүне оештыручылары арасыннан 16 кешедән торган Комиссиянең шәхси составы Дәүләт комитеты боерыгы нигезендә раслана.

4.3. Комиссиянең эше белән аның рәисе җитәкли. Ул булмаган очракта вазифалар аның урынбасарына йөкләнә. Комиссия үзе артыннан өстәмә экспертлар җәлеп итү хокукын калдыра. Бәйге нәтиҗәләрендә шәхси кызыгы булган затлар Комиссия әгъзалары буларак катнаша алмый.

4.4. Комиссия эше аның утырышы барышында башкарыла. Утырышта аның әгъзаларының гомуми саныннан өчтән ике өлешеннән дә киме булмаган саны катнашкан очракта, андый утыраш хокуклы дип санала. Комиссиянең җаваплы серкатибе тавыш бирү хокукына ия түгел.

4.5. Комиссиянең җаваплы сәркатибе киләсе функцияләрне башкара:

әлеге Нигезләмәнең 3.1-3.4 пунктлары нигезендә билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып материалларны кабул итә һәм аларны терки, шулай ук аларны саклауны оештыра;

Комиссиянең утырышын оештыра, документларны әзерли һәм беркетмә төзи.

4.6. Комиссия карары утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы ярдәмендә кабул ителә һәм рәислек итүче белән җаваплы сәркатип тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар саны бертигез булган очракта рәиснең тавышы хәлиткеч булып санала.

4.7. Бәйгедә катнашучы Бәйге нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта ул Бәйге комиссиясенә апелляциягә бирергә хокуклы.

Апелляция ирекле формада язма рәвештә Комиссия рәисе исеменә төзелә һәм Комиссия беркетмәсе Дәүләт комитеты сайтында бастырылганнан соң 3 эш көне эчендә бирелә һәм Комиссия әгъзаларына юнәлтелә.

Комиссии әгъзалары аппеляцияләр кабул итү вакыты тәгәлләнгәннән соң 4 эш көне эчендә аларны карый һәм бергәләп фикер алыша. Карар күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы ярдәмендә кабул ителә һәм Комиссия әгъзаларының күпчелеге катнашкан очракта легитим дип таныла. Тавышлар исәбе бертигез булган очракта Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч дип санала. Комиссиянең җаваплы сәркатибе Комиссия карары нигезендә беркетмә төзи. Беркетмәдә Комиссиянең һәрбер әгъзасының:

апелляцияне кире кагу һәм бастырылган нәтиҗәләрне көчендә калдыру турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында

фикере һәм гомуми нәтиҗә теркәлә.

Беркетмә Комиссия рәисе, аның урынбасары һәм җаваплы сәркатибе тарафыннан имзалана.

Комиссия карары апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча соңгы булып санала, яңадан каралырга тиешле түгел һәм аңа карата суд тәртибендә шикаять бирелә ала.

## 5. Бәйге җиңүчеләре

5.1. Бәйге җиңүчеләре һәм дипломантлары Комиссия утырышы вакытында билгеләнә. Комиссия билгеләрне Бәйгедә катнашучылар алдында дәлилләми.

5.2. Бәйгенең һәр номинациясендә (һәр бүлеккә берер) берәр җиңүче билгеләнә. Җиңүчеләр Дәүләт комитеты исеменнән махсус дипломнар һәм истәлекле призлар белән бүләкләнә.

Үткәрелә торган Бәйге кысаларында Дәүләт комитеты тарафаннан билгеле эшчәнлек өлкәсендә аерым казанышлар өчен махсус призлар оештыру рөхсәт ителә.

5.3. Гаризага теркәлгән материалларны эшкәртү һәм анализлау, аларның объективлыгын бәяләү барышында Комиссия әгъзалары үзара ышаныч, шәхси җаваплылык һәм таләпчәнлек принципларыннан чыгып ун баллы шкала (1 балл – минималь билге, 10 балл – максималь билге) (әлеге Нигезләмәгә 6-нчы номерлы Кушымта) буенча бәя бирә.

5.4. Бәйге комиссиясе һәрбер критерий буенча ун баллы шкала буенча билге куя. Һәрбер критерий буенча җыелган билгеләр суммасы Бәйгедә катнашучының гомуми бәясен билгели.

5.5. «Ел ачышы – 2019» һәм «2019 ел шәхесе – туристлыкны үстерүгә шәхси өлеш керткән өчен» номинациялерендә җиңүчеләр гади тавышлар санын исәпләү ысулы белән тавыш бирү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

5.6. «Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә Татарстан Республикасының туристлык базарын үстерүгә булышлык - 2019» – «Татарстан Республикасының керү туристлыгын һәм эчке туристлыкны популярлаштыруга багышланган иң яхшы материал» номинациясендә Бәйге җиңүчесе халыкара туристлык күргәзмәсенә бару рәвешендәге махсус приз белән бүләкләнә (әлеге Нигезләмәнең 5.2 пукнты нигезендә).

5.7. «Татарстан Республикасы буенча 2019 елның иң яхшы маршруты», «2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы балалар туристлыгы туроператоры», «Татарстан Республикасының 2019 елның иң яхшы туроператоры», «2019 елның иң яхшы туристлык волонтеры», «2019 елның иң яхшы экскурсия җитәкчесе», «2019 ел туристлык истәлекле бүләге», «Татарстан Республикасының урнаштыру оешмасы - 2019», «2019 ел рестораны», «2019 елның Татарстан Республикасының иң яхшы шифаханәсе» номинацияләрендә җиңүчеләр Бәйгене оештыручылар тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктына муафыйк үткәрелгән Бәйге нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

5.8. Бәйгене оештыручы белән алдан килешү буенча катнашучыларга үткәрелә торган Бәйге кысаларында аерым казанышлар өчен кызыксынган оешмалар тарафыннан өстәмә призлар һәм бүләкләр тапшырыла.

5.9. Бәйге нәтиҗәләре Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә төзелгән Дәүләт комитеты боерыгы белән аның имзалану көненнән башлап 3 көн аралыгында раслана.

5.10. Бәйге нәтиҗәләре 2019 елның 25 декабреннән дә соң түгел Дәүләт комитеты тарафыннан (аерым сценарий нигезендә) оештырылучы Бәйге җиңүчеләре һәм дипломантларын бүләкләү тантанасында игълан ителә.

Бәйге нәтиҗәләре турындагы игълан Бәйге җиңүчеләре һәм дипломантларын бүләкләү тантанасы үткәрелә торган көнне Дәүләт комитеты сайтында бастырыла.

5.11. Бәйгене оештыручылар үзләре артыннан

тәкъдим ителгән бәйге материалларын үзәк, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру;

материалларны челтәрле теле- һәм радиокомпанияләр эфирында урнаштыру

хокукларны калдыра.

5.12. Катнашучылар әлеге нигезләмәнең барлык шартлары белән дә тулы һәм берсүзсез килешүне Бәйгегә үзләренең бәйге документларын җибәрү факты белән расслый.

5.13. Катнашучылар аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыкларын Бәйгегә үзләренең бәйге документларын җибәрү факты белән расслый.

2019 елда «Туристлык лидеры»
республикакүләм бәйгесен үткәрү
турында Нигезләмәгә
1-нче номерлы Кушымта

**2019 елда «Туристлык лидеры» республикакүләм бәйгесендә катнашучының**
**СОРАУНАМӘ-ГАРИЗАСЫ**

**Номинация:** ***ЕЛ АЧЫШЫ - 2019***

| |
|---|
| **1. Тутыру датасы** ____________________________________________<br>**2. Оешманың тулы исеме** ____________________________________<br>______________________________________________________________<br>**3. Адрес** ___________________________________________________<br>**4. Лицензия** ________________________________________________<br>**5. Директорның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме**______________<br>**6. Элемтә өчен телефон** _________ **факс** ______________ **E-mail** ________________<br>**7. Web-сайт** ________________________________________________<br>**8. Проектның тасвирламасы**<br><br>**9. Татарстан Республикасында туристлык үсеше өчен әһәмияте**<br><br>**10. Проект яулаган бүләкләр, аның турында басмалар, бәяләмәләр** |
| **11. Бәйге комиссиясе чыгарган нәтиҗәләр** |

Искәрмә: Калын сызык белән бүлеп алынган кисәк бәйге комиссиясе тарафыннан тутырыла.

2019 елда «Туристлык лидеры»
республикакүләм бәйгесен үткәрү
турында Нигезләмәгә
2-нче номерлы Кушымта

**2019 елда «Туристлык лидеры» республикакүләм бәйгесендә катнашучының**
**СОРАУНАМӘ-ГАРИЗАСЫ**

**Номинация: <u>Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә</u>**
***<u>ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫ ҮСЕШЕНӘ БУЛЫШЛЫК - 2019</u>***

| | | |
|---|---|---|
| **1. Тутыру датасы** ________________<br>**2. Оешманың тулы исеме**________________<br>**3. Адрес**________________<br>**4. Барлыкка килү датасы** ________________<br>**5. Җитәкченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме** ________________<br>**6. Элемтә өчен телефон** _________ **факс** ______________ **E-mail** ________________<br>**7. Web-сайт** ________________ | | |
| **8. 2019 елда эш күрсәткечләре** | **Күрсәткечнең саннары** | **Урын** |
| Туристлар санының экспертлы бәяләнеше, кеше саны | | |
| Туристаларга күрсәтелгән хезмәт күләме, сум | | |
| **Районның туристлык паспорты булуы** | | |
| Web-сайты булуы – баллар саны | | |
| Күрсәтмәле материаллар һәм реклама продукциясенең сыйфаты – баллар саны | | |
| **БАРЛЫГЫ:** | | |
| **9. Муиниципаль районда туристлыкны үстерү проекты /программасы** | **Тасвирлама** | |
| **10. Белешмә өчен:** | | |
| Татарстан Республикасында туристлыкны үстерү буенча чараларда катнашу (күрсәтергә) | | |
| Муниципаль берәмлек территориясендә вакыйгалы туристлык чараларын үткәрү. Туристлар санының экспертлы бәяләнеше, кеше саны | | |
| Туристлыкны үстерү программасы, перспективалы проектларның булуы, аларның тормышка ашырылышы | | |
| Муниципаль берәмлектә туристлык үзәге булуы, әйе/юк | | |
| Муниципаль берәмлекне туристлык базарында алга этәрү формалары (күрсәтергә) | | |
| Яңа эшчәнлек формалары (күрсәтергә) | | |
| **Бәйге комиссиясенә презентация продукциясе, шул исәптән булган очракта чит телләрдә дә, тәкъдим ителә** | | |
| **11. Бәйге комиссиясе чыгарган нәтиҗәләр** | | |

Искәрмә: Калын сызык белән бүлеп алынган кисәк бәйге комиссиясе тарафыннан тутырыла.

2019 елда «Туристлык лидеры»
республикакүләм бәйгесен үткәрү
турында Нигезләмәгә
3-нче номерлы Кушымта

**2019 елда «Туристлык лидеры» республикакүләм бәйгесендә катнашучының СОРАУНАМӘ-ГАРИЗАСЫ**

**Номинация:** **Туристлык белеме өлкәсендә**
***ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫ ҮСЕШЕНӘ БУЛЫШЛЫК - 2019***

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1. Тутыру датасы** ____<br>**2. Оешманың тулы исеме** ____<br>**3. Адрес**____<br>**4. Барлыкка килү датасы**____<br>**5. Лицензия** ____<br>**6. Аккредитация** ____<br>**7. Сертификат** ____<br>**8. Җитәкченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме** ____<br>**9. Элемтә өчен телефон** ____ **факс** ____ **E-mail** ____<br>**10. Web-сайт** ____ | | | |
| **11. 2019 елда эш күрсәткечләре** | **Күрсәткечнең саннары** | | **Урын** |
| | План буенча | Чынында | |
| 1.Туристлык белгечлекләре буенча белем алучыларның гомуми саны, кеше саны, шул исәптән (белгечлекләр буенча бүленеш) | | | |
| - | | | |
| - | | | |
| Шулардан:<br>- турфирмалар белән;<br>- кунакханәләр белән<br>шартнамәләр нигезендә | | | |
| 2. 2018/19 уку елында туристлык белгечлекләре буенча чыгарылган (кеше саны) | | | |
| 3. Турфирмалар белән үзара эш итү формалары (күрсәтергә) | | | |
| 4. Кунакханәләр белән үзара эш итү формалары (күрсәтергә) | | | |
| 5. Татарстан Республикасының туристлык буенча Дәүләт комитетының туристлык индустриясе өлкәсендә кадрлар әзерләүгә булышлык итү буенча Методик киңәшмәсендә катнашу (кайсы икәннәрен күрсәтергә) | | | |
| 6. 2019 елда тормышка ашырылган Татарстан Республикасында туристлыкны үстерү буенча проектлар (кайсы икәннәрен күрсәтергә) | | | |
| 7. Туристлык базарында алга этәрү формалары (күрсәтергә) | | | |
| 8. Яңа эшчәнлек формалары (күрсәтергә) | | | |
| **9. Бәйге комиссиясе чыгарган нәтиҗәләр** | | | |

Искәрмә: Калын сызык белән бүлеп алынган кисәк бәйге комиссиясе тарафыннан тутырыла.

2019 елда «Туристлык лидеры»
республикакүләм бәйгесен үткәрү
турында Нигезләмәгә
4-нче номерлы Кушымта

**2019 елда «Туристлык лидеры» республикакүләм бәйгесендә катнашучының**
**СОРАУНАМӘ-ГАРИЗАСЫ**

**Номинация: Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә**
***<u>ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫ ҮСЕШЕНӘ БУЛЫШЛЫК - 2019</u>***

| |
|---|
| **1. Тутыру авторы** ______________________________________________<br>**2. Авторның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме** ____________________<br>**3. Эш урыны, вазифасы** ___________________________________________<br>**4. Басманың исеме (баш исеме)** ____________________________________<br>**5. ММЧ исеме** _________________________________________________<br>**6. Бастыру датасы** _______________________________________________<br>**7. Басмага сылтама** ______________________________________________<br>**8. Элемтә өчен телефон** ______________ **E-mail** ____________________<br><br>**9. Кушымталар:**<br>- массакүләм мәгълүмат чараларында басма – PDF форматында басманың сканы, массакүләм мәгълүмат чарасының мөхәррият башлыгы тарафыннан расланган материалның бастырылу датасын, авторның (авторларның) исемен күрсәтүче мөхәррият белешмәсе;<br>- ТВ өчен видеосюжет – видеосюжетка сылтама;<br>- Интернет челтәрендә басма – битләрнең скриншоты. |
| **10. Бәйге комиссиясе чыгарган нәтиҗәләр**<br><br>**Катнашучылар эшенең сыйфатын бәяләү критерийлары**<br>- игълан ителгән номинациягә туры килү,<br>- материалда бәйге темасын иң тулы һәм ачык гәүдәләндерелеше,<br>- хикәяләү теле һәм стиленың төгәллеге һәм аңлаешлыгы,<br>- профессионализм (материалның компетентлыгы, тирәнлеге, зарурлыгы) |

Искәрмә: Калын сызык белән бүлеп алынган кисәк бәйге комиссиясе тарафыннан тутырыла.

2019 елда «Туристлык лидеры»
республикакүләм бәйгесен үткәрү
турында Нигезләмәгә
5-нче номерлы Кушымта

**2019 елда «Туристлык лидеры» республикакүләм бәйгесендә катнашучының**
**СОРАУНАМӘ-ГАРИЗАСЫ**

**Номинация:** ***2019 ЕЛ ШӘХЕСЕ – туристлыкны үстерүгә шәхси өлеш керткән өчен***

**1. Тутыру датасы** ___________________________________________

**2. Катнашучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме** _________________

**3. Туган көне, ае һәм елы** _____________________________________

**4. Эш урыны һәм вазифасы** (булган очракта) __________________________

**5. Туристлык өлкәсендә эш стажы** ________________________________

**6. Профессиядә булган шәхси казанышлары:**

**7. Бәйге комиссиясе чыгарган нәтиҗәләр**

Искәрмә: Калын сызык белән бүлеп алынган кисәк бәйге комиссиясе тарафыннан тутырыла.

2019 елда «Туристлык лидеры»
республикакүләм бәйгесен үткәрү
турында Нигезләмәгә
1-нче номерлы Кушымта

**Катнашучыларның материаллары сыйфатын бәяләү критерийлары**

| Критерий исеме | Баллар | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Игълан ителгән номинациягә туры килү | | | | | | | | | | |
| Бәйге гаризасын Бәйге турындагы Нигезләмә таләпләренә туры китереп төзү | | | | | | | | | | |
| * 2019 елда башкарылган эш күрсәткечләре:<br>- туристлар санының экспертлы бәяләнеше<br>- туристларга күрсәтелгән хезмәт күләме<br>- муниципаль берәмлек территориясендә вакыйгалы туристлык чараларын үткәрү<br>- Татарстан Республикасында туристлыкны үстерүгә юнәлтелгән чараларда катнашу | | | | | | | | | | |
| * Районның туристлык паспорты булуы | | | | | | | | | | |
| * Районның web-сайты булуы | | | | | | | | | | |
| * Туристлыкны үстерү программасы, перспективалы проектларның булуы, аларның тормышка ашырылуы | | | | | | | | | | |
| * Мәгълүмати туристлык үзәге булуы | | | | | | | | | | |
| * Муниципаль беремлекнең туристлык базарында алга этәрү формалары | | | | | | | | | | |
| ** 2019 елда башкарылган эш күрсәткечләре:<br>- туристлык белгечлекләре буенча укучаларның гомуми саны<br>- 2018/19 уку елында туристлык белгечлекләре буенча чыгарылган | | | | | | | | | | |
| ** Турфирмалар белән үзара эш итү формалары | | | | | | | | | | |
| ** Кунакханәләр белән үзара эш итү формалары | | | | | | | | | | |
| ** Татарстан Республикасы туристлык буенча Дәүләт комитетының туристлык индустриясе өлкәсендә кадрларны әзерләүдә булышлык итү буенча Методик киңәшмесендә катнашу | | | | | | | | | | |
| ** 2019 елда тормышка ашырылган Татарстан Республикасында туристлыкны үстерү буенча проектлар | | | | | | | | | | |
| ** Уку йортын туристлык базарында алга этәрү формалары | | | | | | | | | | |
| *** Бәйге темасын материалда иң тулы һәм ачык гәүдәләндерелеше | | | | | | | | | | |
| *** Хикәяләү теленең һәм стиленың төгәллеге һәм аңлаешлыгы | | | | | | | | | | |
| *** Профессионализм (материалның компетентлыгы, тирәнлеге һәм зарурлыгы) | | | | | | | | | | |

* Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә *ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫ ҮСЕШЕНӘ БУЛЫШЛЫК* – 2019 номинациясендә бәяләнә (2-нче номерлы Кушымтадагы сораунамә-гариза нигезендә)
** Туристлык белеме өлкәсендә *ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫ ҮСЕШЕНӘ БУЛЫШЛЫК – 2019* номинациясендә бәяләнә (3-нче номерлы Кушымтадагы сораунамә-гариза нигезендә)
*** Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә *ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫ ҮСЕШЕНӘ БУЛЫШЛЫК – 2019* номинациясендә бәяләнә (4-нче номерлы Кушымтадагы сораунамә-гариза нигезендә)